СОВЕТ
МОЛВИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУЛЛА ИЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09 июль 2025 ел Мулла Иле ав. № 194

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " № 131 – ФЗ, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районының Мулла Иле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын паспортлаштыру.

2. Мулла Иле авыл җирлеге башкарма комитетына җирлекнең әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) , шулай ук Мулла Иле авылы, Яна урам, 3 (җирлекнең административ бинасы), Мулла Иле авылы, Үзәк урам, 17а йорты (мәдәният йорты бинасы),Зур Отэк авылы , Яшел урам, 21а йорты (мәдәният йорты бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга

Мулла Иле авыл жирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Г.Сәләхиев